| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 апрель г.Казань № 235

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы һәм мөхбир әгъзасы исеме өчен оклад билгеләү һәм фән докторы һәм кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә өчен өстәмә түләү турында» 2002 ел, 22 декабрь, 657 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы һәм мөхбир әгъзасы исеме өчен оклад билгеләү һәм фән докторы һәм кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә өчен өстәмә түләү турында» 2002 ел, 22 декабрь, 657 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 ел, 4 март, 124 нче; 2007 ел, 17 гыйнвар, 1 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 639 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасына һәм мөхбир әгъзасына ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе әгъзаларын матди бүләкләү системасын камилләштерү һәм социаль яклауны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хокукый әгъзасына ай саен бирелә торган акчалата түләү – 75 мең сум, Татарстан Республикасы Фәннәр

академиясенең мөхбир әгъзасына ай саен бирелә торган акчалата түләү 35 мең сум тәшкил итә;»;

өченче абзацта «исем өчен оклад» сүзләрен «ай саен бирелә торган акчалата түләү» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «исеме өчен окладлар билгеләнгән» сүзләрен «буларак ай саен бирелә торган акчалата түләүләр алучы» сүзләренә алмаштырырга;

2 һәм 3 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин